**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

13.08.2019 № 286

**2019–2023 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы көрәшү комплекслы планын Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары турында**

Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2018 елның 28 декабрендә Пр-2665 номеры белән расланган 2019–2023 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы көрәшү комплекслы планын Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру максатларында:

1. Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улын 2019–2023 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы көрәшү комплекслы планын (алга таба – Комплекслы план) Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру эшчәнлеген оештыру һәм контрольдә тоту өчен җаваплы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссия аппаратын Комплекслы планны Татарстан Республикасында гамәлгә ашыруны төп башкаручы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссия аппаратына:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының Комплекслы планны гамәлгә ашыру эшчәнлеген координацияләүне һәм методик яктан тәэмин итүне башкарырга;

Ел саен 25 декабрьгә кадәр Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссиягә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан киләсе календарь елга Комплекслы план чараларын гамәлгә ашыру планы күчермәсен җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ